Раслыйм:
Актаныш муниципаль район башлыгы
_______________ Л.Р.Зарипов

**Нигезләмә**

**III нче регионара «Актаныш гармуннары» фестиваль-конкурсы кысаларында “Авылларда гармун моңнары” гармунчылар җыены**

**1. Гомуми нигезләмә “Авылларда гармун моңнары” регионара** гармунчылар җыены 2023 елда Актаныш муниципаль районы Чөгәнә авылында үткәрелә.

1.1. **“Авылларда гармун моңнары”** регионара гармунчылары җыены татар авылларын, халыкның традицияләрен, гармун төрләрен саклау, пропагандалау һәм үстерү, талантлы башкаручыларны ачыклау, иҗатка кызыксынуларын көчәйтүгә юнәлдерелгән.

1.2. Чара ике елга бер тапкыр үткәрелә.

1.3. Гармунчылар җыены Татарстан Республикасында 2023 ел - Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын 09.03.2023 ел. 584-нче санлы Указы һәм планы нигезендә оештырыла.

1.4. Гармунчылар җыенын үткәрү буенча чараларны финанслау Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы һәм спонсорлар хисабына башкарыла.

**2. Гармунчылар җыенның оештыручылары:**

2.1. Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты.

2.2.“Иске Сәфәр авыл мәдәният йорты” муниципаль бюджет учреждениесының “Баламишкин” гармунчылар ансамбле

2.3. Актанышбаш авыл жирлеге.

2.4. Ә.Авзалова ис. Актаныш район мәдәният йорты

2.5. Гармунчылар җыенын үткәрү һәм йомгак ясау өчен конкурсны оештыручылардан торган оештыру комитеты төзелә.

**3. Гармунчылар җыенының максатлары һәм бурычлары:**

3.1. Җыенның максаты: гармун төрләрендә уйнаучыларны барлау, халкыбыз традицияләрен саклау һәм үстерү, һәвәскәрләрне һәм профессионалларны берләштерү, тәҗрибә уртаклашу өчен шартлар тудыру, һөнәри осталыкны арттыру.

3.2. Җыенның бурычлары-ансамбльләр, аерым башкаручыларны бер мәйданга җыю, бер-берсенә таныту, аралаштыру, аларның башкару осталыгын арттыру, халык көйләрен, оста уйнаучыларнын алымнарын киң пропагандалау, репертуарны баету, иҗат эшчәнлеген активлаштыру, авыл сәхнәләренә, “капка алларына” онытылган гармун моннарын, гармунлы җырларны, биюләрне кайтару, авылларда гармунчыларны устеру, яшь буынга милли патриотик тәрбия бирүгә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү.

**4. Гармунчылар җыенында катнашучылар**

4.1.Җыенда һәвәскәр, профессиональ гармунчылар ансамбльләре һәм аерым башкаручылар катнаша ала.

4.2. Катнашучыларның яше 10 яшьтән һәм өлкәнрәк.

4.3. Катнашучыларның төп составын Ык, Агыйдел, Сөн, Кама буе зонасының татар торак пунктларының гармонистлары тәшкил итәчәк.

4.4. Җыенда баян, хромка, тальян, саратский, вараксин, һ.б гармун төрләрендә татар халык һәм милли әсәрләрен башкаруны күздә тота.

**5. Гармунчылар җыенын үткәрү шартлары һәм тәртибе.**

5.1. Җыенда катнашу бушлай.

5.2. Җыен 2023 нче елның 8 июлендә Татарстан Республикасының Актаныш районы Чөгәнә авылында үткәрелә.

- **заявкалар** 6 июль 2023 елга кадәр кабул ителә

- һәвәскәр, профессиональ гармунчылар ансамбльләре һәм аерым башкаручылар арасында урыннар һәм номинацияләр башкару осталыгына карап чыгарыла

**ялгыз башкаручылар** арасында:
10-17 яшь
18-25 яшь
26-45 яшь
45 яшьтән югары.

**Ансамбльләр арасында**
- Балалар ансамбле
- Зурлар ансамбле

**Номинацияләр**
-Иң яхшы авыл көен уйнаучы гармунчылар ансамбле (командасы).
-Иң оста гармунчы хатын-кыз
-Иң оста гармунчы ир-ат
-Иң кечкенә гармунчы
-Иң өлкән гармунчы
-Иң оста уйнап җырлаучы (ретро татар җырларына өстенлек бирелә)
-Тамашачы мәхәббәтен яулаучы

5.3.Жюри урыннарны чыгарганда үзенең тәкьдимнәрен кертә ала.

**6. Өстәмә мәгълүмат**

6.1. Оештыру комитетының адресы: Актаныш район мәдәният һәм социаль агарту җитәкчесе Латыйпов Назил Назиф улы, тел: 89376148090

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Сәфәр авылы, Харунов Илдус Һади улы, тел: 89393907603

Район мәдәният йорты метод.үзәк җитәкчесе Гайнутдинова Альбина Финус кызы, тел: 89274827552.

Чөгәнә авыл клуб мөдире Арсланова Алсу Ильфар кызы. тел: 89274606193

Заявкалар : alba-gai@yandex.ru адресы буенча кабул ителә.

**“Авылларда гармун моңнары” регионара җыенның программасы**

**8.07.2023 ел.**

11.00- 12.00 Регистрация (Чөгәнә авылы, “Равил аланы”)

12.00-13.00 Көндезге чәй

13.00-13.45 III нче регионара «Актаныш гармуннары» җыенын ачу тантанасы

14.00-16.00 Гармунчылар бәйгесе

16.00- 17.00 Кичке аш

17.00-18.00 Чөгәнә авылы урамнары буйлап махсус маршрут буенча гармунчылар парады

18.00-19.30 “Көй тартыш” бәйгесе, җиңүчеләрне бүләкләү, Фестиваль-җыенны ябу тантанасы.

Кушымта №1

**Гариза-анкета**

III нче регионара **“Авылларда гармун моңнары”** регионара
татар гармунчылары җыены

1. Шәһәр, район

2. Ансамбль җитәкчесе Ф. И. О (Аерым башкаручы, ФИО); туган елы

3. Ансамбльдә ничә кеше

4. Ансамбльнең, аерым башкаручының бүләкләре

5. Репертуар (әсәр авторларын, яңгырау вакытын күрсәтеп)

6. Нинди конкурсларда катнашулар турында мәгълүмәт

7. Телефон (җитәкченең, катнашучының)

8. Җибәрүче оешманың җитәкчесе

«___» _________________2023ел                    ___________________________

(подпись, печать)

Приложение № 1

**Заявка-анкета**

для участия на III Межрегиональном фестивале татарских гармонистов
**“Авылларда гармун моңнары”**

1. Город, район
2. Ф.И.О. руководителя ансамбля (отдельного исполнителя); год рождения
3. Количество участников
4. Награды
5. Репертуар (с указанием авторов произведений, времени звучания)
6. Участие в других конкурсах
7. Телефон (руководителя, участника)
8. Руководитель направляющей организации

«___» ________________2023г. __________________________
(подпись, печать)